# Шигъри сандык

№ 9 Сентябрь 2023 ел



Укымыймын, дустым, китап,
Яратмыймын ул шөгелне –
Диеп әйтәсен син, алдап,
Тик алдыйсын шул узеңне...

Ачу саклап та йөрисең,
Сүзләр сызып, күктә очып,
Әмма башканы тиргисең,
Гафләтнең билен кочып.

Өтерләрдә тын аласың,
Нокта белән тәмам көнең.
Яшәп, сизми калмассың
Узгәрешен җөмләләрнең.

Кемнекедер ул сиксән бит,
Кемдер укый тик утызын,
Укыймыйча да китәләр бит,
Сала алмыйча авазын.

Кыенлыкка кара көлеп, - ди
Тормыш китабы дәшә-
Һәр көннең ямен күреп,
Мәгънәсен саклап яшә!

*РАЯН ШАКИРОВ*